| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**2020 елның 2 сентябре** **Чистай шәһәре** **№ 57/4**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында" гы 2019 елның 26 сентябрендәге 47/5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. "Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында" гы 2019 елның 26 сентябрендәге 47/5 номерлы Чистай муниципаль районы Советы карарына түбәндәге редакциядә 7.1 пунктын бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

"7.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү дигәндә хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматтан затларның чикләнмәгән даирәсеннән ирекле файдалана алу мөмкинлеген булдыруга юнәлдерелгән һәм Интернет челтәрендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнары (программалары) , муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, муниципаль мөлкәтне сату турында һәм аны сату йомгаклары турында мәгълүмати хәбәрләр урнаштыру керә торган чаралар аңлашыла".

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru)

бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (www.chistopol.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов